# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында" Татарстан Республикасы Законының 13 статьясына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 16 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында" 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 13 статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 ( I өлеш); 2007, № 8; 2009, № 6; № 9 – 10; 2011, № 4 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2011, 18 октябрь), беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә: "Дәүләт мөлкәтен бәясен игълан итмичә сату-алу шартнамәсе "Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында" Федераль законның 32 статьясындагы 5 пунктында билгеләнгән срок чыккан мизгелдән биш эш көне дәвамында төзелә.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2012 елның 3 марты
№ 13-ТРЗ